Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
«Юлсубино авыл җирлеге» составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 24 ноябре № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино авыл җирлеге" составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2023елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль "Юлсубино авыл җирлеге" составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешесеннән, мобилизациялэнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сәләтсез гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан гайре 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

1. Юлсубино торак пунктында урам утларын ремонтлау

2.Юлсубино авылы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау

3. Юлсубино авылында яшәүчеләргә су алу, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау

4.Халык күплэп ял итэ торган урыннарны(парклар, скверлар,спорт мэйданчыклары һәм халык күплэп ял итэ торган башка урыннарны) төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү.

5. Юлсубино авыл торак пункында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чаралары аша халыкның ялын оештыру

6. Юлсубино авылында кышкы һәм җәйге юлларны карап тоту

7. Юлсубино авыл торак пунктында коммуналь калдыклар өчен контейнер мэйданчыгы төзү һәм контейнерлар сатып алу

8. Янгынны сүндерү өчен янгын җинсәләре сатып алу

9. Балалар өчен уен мэйданчыгы төзү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт; Ямаш авылы,Х.Такташ урамы, 3в йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов